**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«01» ___08___ 2019 ел.** **№ 245**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 мартындагы 67 номерлы«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешне кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына мәдәният, сәламәтлекне саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм федераль учреждениеләр тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне камилләштерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасының «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирә:

1.Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 мартындагы 67 номерлы«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 бүлекнең 3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаган башка затлар керә алмый.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов